**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023 елның 25 декабре** **153-РС номер**

# КАРАР

## 2024 елга Лаеш муниципаль районы Советының эш планы турында

Лаеш муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Лаеш муниципаль районы Башлыгы- Совет рәисе вазифаларын башкаручы Т.П.Борһанованың Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елга эш планы турындагы мәгълүматларын тыңлап һәм фикер алышып, Лаеш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елга эш планын (кушымта)расларга.
2. Район Советының даими комиссияләренә, Лаеш муниципаль районы Советы аппаратына һәм Башкарма комитетына Лаеш муниципаль районы Советы каравы өчен планда каралган мәсьәләләрне вакытында әзерләүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы** **Т.П.Борһанова**

*Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның __ __ номерлы карарына кушымта*

**2024 елга Лаеш муниципаль районы Советының эш планы**

| № т/б | Чаралар | Башкару срогы | Әзерлек өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Район Советы сессияләрен әзерләүне һәм үткәрүне оештыру | ел дәвамында | Район Советы, депутат комиссияләре |
| 2. | Район Советының даими комиссияләре утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне оештыру | Эш планы буенча | Район Советы, депутат комиссияләре |
| 3. | Актуаль мәсьәләләр буенча ачык тыңлаулар үткәрү | ел дәвамында | Район Советы, Башкарма комитет |
| 4. | «Кама ягы» газетасында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы» нда һәм Лаеш муниципаль районы сайтында район Советы эшчәнлеген яктырту | ел дәвамында | Район Советы |
| 5. | Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча муниципаль сайлаулар һәм җыеннар әзерләгәндә җирлек Советларына оештыру-методик һәм хокукый ярдәм күрсәтү | ел дәвамында | Район Советы, Башкарма комитет |
| 6. | Район Советы депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары белән очрашуларын үткәрү(ТР Дәүләт Советы белән килешү буенча) | ел дәвамында | Район Советы, Башкарма комитет |
| 7. | «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы " муниципаль берәмлегенең норматив-хокукый актларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында | ел дәвамында | Район Советы |
| **Лаеш муниципаль районы Советы сессияләре каравына кертелә торган мәсьәләләр** | | | |
| 1) | Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының 2023 елдагы эш йомгаклары һәм 2024 елга бурычлары турында | I квартал | Башкарма комитет, Финанс-бюджет палатасы, Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 2) | Лаеш муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2023 елдагы эшчәнлеге һәм 2024 елга бурычлары турында хисап турында | I квартал | Районның контроль-хисап палатасы |
| 3) | Лаеш муниципаль районы Советы карарларына үзгәрешләр кертү турында | I квартал | Район Советы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4) | Лаеш муниципаль районы территориясендә торак төзелеше турында | II квартал | Башкарма комитет |
| 5) | Лаеш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында | II квартал | Башкарма комитет |
| 6) | 2023 елга Лаеш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында | II квартал | Башкарма комитет,районның финанс-бюджет палатасы |
| 7) | Лаеш муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында | II квартал | Район Советы |
| 8) | Лаеш муниципаль районында мәгариф системасын үстерү турында | II квартал | Башкарма комитет |
| 9) | Лаеш муниципаль районы Советы карарларына үзгәрешләр кертү турында | II квартал | Район Советы |
| 10) | Лаеш муниципаль районының 2024 елга социаль – икътисади үсеш фаразы турында | III квартал | Башкарма комитет |
| 11) | Мәдәният учреждениеләре эшендә актуаль проблемалар һәм нәтиҗәлелекне арттыру турында | III квартал | Башкарма комитет |
| 12) | Лаеш муниципаль районында экстремизм һәм терроризмны профилактикалау турында | III квартал | Башкарма комитет |
| 13) | Лаеш муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү турында | III квартал | Башкарма комитет |
| 14) | Лаеш муниципаль районы Советы карарларына үзгәрешләр кертү турында | III квартал | Район Советы |
| 15) | Лаеш муниципаль районының 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына бюджетын раслау турында | IV квартал | Башкарма комитет,районның финанс-бюджет палатасы |
| 16) | Лаеш муниципаль районында җирле үзидарә органнарының кадрлар потенциалы һәм муниципаль хезмәтне үстерү турында | IV квартал | Район Советы, Башкарма комитет |
| 17) | Лаеш муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында | IV квартал | Башкарма комитет |
| 18) | Авыруларны профилактикалау һәм халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру турында | IV квартал | Башкарма комитет, Лаеш үзәк район хастаханәсе (килешү буенча) |
| 19) | Лаеш муниципаль районы Советының 2025 елга | IV квартал | Район Советы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эш планы турында | | |
| 20) | Лаеш муниципаль районы Советы карарларына үзгәрешләр кертү турында | IV квартал | Район Советы |

**Лаеш муниципаль районы Советы карарын**
**Килештерү кәгазе**

**Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елга эш планы турында**

**Әзерләде:**
Район Советы Аппаратының оештыру бүлеге начальнигы урынбасары

С.С.Долгова

(вазифа, имза, фамилия һәм инициаллар, эш телефоны)

**Килешенде:**

1. Район Советы Аппараты җитәкчесе ___________________ Р.Т.Гарифуллин

2. Район Башкарма комитетының юридик бүлегенең баш белгече ___________________ Е.П.Федорина

**Тарату:**
(әлеге карарны җибәрергә кирәкле адресатлар исемлеге)

1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________
4. ______________________________